2023
ГОД ПЕДАГОГА
И НАСТАВНИКА



# «Гиззатуллинар династиясе»

**Кереш**

«Укытучы булып туарга кирәк», - ди халык. Бу сүзләрдә хаклык та, дөреслек тә бардыр шул. Күпме түземлек, сабырлык, тәртип, мөлаем, җыйнаклык, вакытны дөрес бүлә белү һәм тагын бик күп сыйфатларга ия булу кирәк. Балаларны ярату, гомерең буе аларга үрнәк булу, һәм дә алар белән дөрес аралашу, аңлашу – күпме көч таләп итә бу һөнәр кешесеннән. Күп эзләнү, осталыгыңны, белемеңне арттыру да укытучы өчен бик әһәмиятле.

Күренекле язучы Фәнис Яруллин укытучыларга юкка гына «Сез иң гүзәл кеше икәнсез!» – дип әйтмәгән. Чыннан да, кирәк чакта безне мактаучы да, яклаучы да, киңәшче дә - укытучылар. Укытучылар турында язылган әдәби әсәрләр дә шактый күп.

Кеше хезмәте белән табигатьне үзгәртә дип әйтәләр. Ә укытучы хезмәте Кешенең үзен формалаштыруы белән кыйммәтле һәм гүзәл.

Җир йөзендә бик күп һөнәрләр бар. Шулар арасында иң дәрәҗәлесе укытучы һөнәредер. Минемчә, укытучыдан башка дөньяны күз алдына да китереп булмас иде. Чөнки җир йөзендәге барлык профессия кешеләренә дә Укытучы белем һәм тәрбия биргән бит. Дөнья серләренә төшенергә дә өйрәтә укытучы, остаз, мөгаллим дә.

«Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк», - ди халык. Сулар ага – ярлары кала. Гомер үтә - кешеләр кала. Кешеләр күчә - нәселе кала, эшләгән эшләре, кылган яхшылыклары, изгелекләре җирдә, киләчәк буыннар хәтерендә, күңелендә кала.


Гаиләнең укытучылар династиясе. Нәрсә ул династия?

Династия ул грек сүзеннән алынган һәм тәрҗемәсе «хакимлек» дигәнне аңлата.

Ожегов сүзлегеннән без күчерелмә мәгънәдә нәселдән нәселгә тапшырылучы хезмәт сөючеләр, хезмәт йолалары аңлатуын белдек. Белем бирү өлкәсендә эшләүче яки эшләгән вәкилләр, туганлык җепләре бәйләнгән берничә педагог нәселе укытучылар династиясе булып санала.

**Чыгышлары белән Чистай районы Иске Роман авылына барып тоташкан Гыйззәтуллиннар нәселенең укытучылар династиясе**

**Шәһит Гыйззәтуллин**




Шәһит Гыйззәтуллин 1925 елны Иске Роман авылында туа. 15 яшьлек егетне Паратск (хәзерге Яшел Үзән) шәһәрендәге ФЗӨ мәктәбенә укырга җибәрәләр. Сугыш башлангач, Ижевскида сугыш кораллары ясаучы цехта эшли.

Кем булып кына эшләми ул: тракторчы, шофер, эретеп ябыштыручы, авыл советы рәисе.

1963нче елда Чистайда укытучылар өчен бер еллык курсларны тәмамлап, Иске Роман сигезьеллык мәктәбендә физкультура укытучысы булып эшли. Узенең өч баласының да укытучылар булуын тели ул. Әти кешенең теләге тормышка аша: уллары Рәшит, Рәис, кызы Әлфия- Алабуга дәүләт педагогия институтын тәмамлап, физика, математика укытучысы булып эшли башлыйлар.




**Рәшит Гыйззәтуллин**



Мәктәптә укыганда ук техник фәннәргә тартылган егет 1974 нче елда Алабуга педагогия институтының физика-математика факультетына укырга керә. Кулына диплом алгач, ул педагогик эшчәнлеген Яңа Чишмә районы Чаллы башы сигезьеллык мәктәбендә физика укытучысы, директор урынбасары булып эшли башлый. Соңрак ул Лебедка, Исләй, Иске Роман мәктәпләрендә 20 ел директор була.

1986 нчы елда Иске Роман авылында яңа мәктәп бинасы төзелә башлый. Рәшит Гыйззәтуллин мәктәпне сафка бастыру, аның матди-техник базасын яңарту өчен бик күп тырышлык куя. «Хезмәтемнең төп күрсәткече – укучыларымның минем профессияне сайлавы», - ди ул горурланып. Рәшит Гыйззәтуллин – Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән министрлыкларының Мактау грамотасы белән бүләкләнгән.





**Шәһит Гыйззәтуллинның килене-Розалия Рамазанова (Гыйззәтуллина)**

1979 нчы елны Арча педагогия училищесын тәмамлый. Яшь кадрны Чистай районы Исләй авылына эшкә билгелиләр. 5 ел Исләй сигезьеллык мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты укыта. Күрше Иске Роман авылы егетенә кияүгә чыккач, шул авылда 35 ел балаларга белем һәм тәрбия бирә, озак еллар укыту эшләре буенча директор урынбасары булып эшли. Укытучыларга кытлык булганга, төрле фәннәр укытырга туры килә аңа: рус теле, тарих, биология, химия, хезмәт, хәтта немец теле, татар теле. «Мин үземне күп профильле тракторчы белән чагыштыра идем, » – ди ул.

Розалия Гыйззәтуллина – 20 елга якын районда, республикада татар теле һәм әдәбияты буенча эксперт булып торды. РСФСРның халык мәгарифе отличнигы, Россия Федерациясе Халык мәгарифе почетлы хезмәткәре билгесенә ия. Укучыларның күбесе Розалия Рамазановна (Гыйззәтуллина) юлыннан китә - укытучы һөнәрен сайлый, һәм бу, мөгаен, үз эшенә карата мәхәббәт, хөрмәт тәрбияли белүеннәндер.

Розалия тормыш иптәше – Иске Роман авылының укытучы Гыйззәтуллиннар династиясеннән булган **Рәшит Гыйззәтуллин.**



**Рәшит- кызы Гөлназ (Хәнәфиева)**



Ул 2003 нче елны Иске Роман урта мәктәбен тәмамлагач, Татар Дәүләт Гуманитар Педагогик Университетының физика факультетына укырга керә. Аны тәмамлагач, шул ук уку йортында методист, Казан шәһәренең Приволжский районында ИМЦда, КФУда укыту-методик эш буенча специалист булып эшли.

Ә 2017 нче елдан ул Чистай шәһәренең 5 нче мәктәбендә физика, математика, информатика укытты, аннары 10 нчы мәктәптә эшли, армый-талмый балаларга белем һәм тәрбия бирүче мөгаллим ул. Хәзерге вакытта Мәскәү шәһәрен дә яшиләр.

**Әлфия Гыйззәтуллина (Җиһаншина)**



Институт тәмамлагач, Әлфия апаны  Чистай районы Шонталы сигезьеллык мәктәбенә билгелиләр. Яшь булса да, гадилеге, кеше күңелен аңлый белүе белән укучылар, укытучылар, авыл халкы арасында зур хөрмәт казана.

1982 нче елдан ул Яуширмә урта мәктәбендә физика укытучысы булып эшли башлый. Шулай ук тәрбия эшләре буенча, соңрак укыту эшләре буенча директор урынбасары була. Укучыларның яраткан укытучысы, мөгаллимнәрнең остазы булган ярдәмчел, кече күңелле, үз эшенең остасы булган Әлфия Шәһитовна һәркемнең йөрәгенә ачкыч таба алды.

Әлфия апаның улы **Ранил Җиһаншин** да әнисе, бабасы эшен дәвам



итте. Ул  Татар Дәүләт Гуманитар Педагогик Институтының филология бүлеген тәмамлады. Стажировканы Америка Кушма Штатларында үтте һәм бүгенге көндә Пенсильвания штатының Питтсбург шәһәрендә яши һәм эшли.

Шәһит бабайның кече улы **Рәис Гыйззәтуллин** 1985 нче елны Яуширмә урта мәктәбенә эшкә билгеләнәләр. Бер елдан соң Татар Сарсазы авылында төпләнә. Бу авылда яңа мәктәпкә Рәис абыйны директор итеп билгелиләр. Яңа мәктәпнең материаль- техник базасын булдыруга бик зур өлеш кертә, бу җаваплы постта ул чирек гасырга якын эшли.





**Резидә Гыйззәтуллина** физика, математика, информатика фәннәреннән белем бирә, озак еллар тәрбия эшләре буенча директор урынбасары була.

**Резидә** тормыш иптәше – **Рәис Гыйззәтуллин.**


Шәһит бабамның энесе **Рәхимҗан Гыйззәтуллинның** да балалары, оныклары укытучылар династиясен дәвам итүчеләр.



**Миләүшә Гыйззәтуллина (Гомәрова)** – Алабуга педагогия институтын тәмамлагач, 1990 нчы елда Чистай районы Мөслим урта мәктәбенә математика, информатика укытучысы булып кайта. 1992 нче елда Уракчы башлангыч мәктәбендә эшли, 2002 нче елдан ул Татар Сарсазы урта мәктәбендә эшли, ә 2010 нчы елдан Чистай шәһәренең 6 нчы номерлы мәктәбендә физика – математика фәннәрен укытып балаларга белем һәм тәрбия бирә.



Миләүшәнең кызы – **Таңсылу Гомәрова (Гарифуллина)** Чистай шәһәре педагогик колледжны тямамлагач, 2013 елда КФУ га читтән торып укырга керә һәм шул елны Чистай шәһәренең 3 нче номерлы «Кояшкай» балалар бакчасында тәрбияче булып эшли. Баларны бик ярата, бөтен назын, күңелен биреп баларны тәрбияли. Үз эшен бик яратып эшли. Алтын куллы Таңсылу бик ярата чигәргә, бәйләргә, рәсемнәр ясарга, кулынан бар эштә килә.



Рәхимҗан бабайның килене **Резида Гыйззәтуллина (Кабирова)** – башлангыч сыйныф укытучысы. Ул Арча педагогия училещесын тәмамлагач, Чистай районы Шонталы мәктәбендә эшли башлый.

Резида Нигъмәт кызы Чистайда 5нче мәктәптә озак еллар башлангыч сыйныфларда эшли. Ягымлы, шат күңелле, җырга-моңга гашыйк бу укытучы мәктәпнең йөзек кашы булып тора.

2002 нче елдан ул Чистай шәһәренең 4 нче номерлы мәктәбендә эшли башлый, милли белем һәм тәрбия эшләре буенча директор урынбасары була.



Резиданың кызы **Рәмзия (Гыйззәтуллина) Афлятунова** - инглиз теле укытучысы.

Хәзерге вакытта Чистайтай медучилищеда укыта.

Резиданың кызы **Шангараева Лилия (Гыйзатуллина)**



2007 Чистай шәһәрендә МБОУ ,, ООО 6 " мәктәптә педагог организатор булып эшли башлый, 2011 Управление образования дә эшли. ГБУ,, Чистопольский балалар йортында социальный педагог булып эшли.

Укытучылар гаиләсендә туып-үскән балаларның берсе булса да мөгаллимлек хезмәтен сайламый калмый. Мәктәптә укыган елларда укытучы баласы булуның үзенә күрә кыенлыклары булса да, әти-әнисенә охшарга тырышып аларның юлын дәвам иткән династияләр шактый. Безнең династия шундыйлардан, нәселебездә укытучылар чылбыры өзелми, мөгаллимнәр династиясе үз һөнәрен дәвам итә дигән сүз.

Нәсел агачы - шәҗәрәне барлаганда, зур горурлык хисләре кичердек. Гомерләрен мөгаллимлек эшенә багышлаган, бу эшкә мәхәббәт уяткан әби-бабаларыбызның, абый-апаларыбызның тормыш юллары соклану һәм кызыксыну уята. Озак еллар буена эстафета булып күчә барган әлеге һөнәргә безнең гаиләнең мәхәббәте әле дә сүнми, сүрелми. Һәм без үзебезнең нәкъ менә шушы олугъ, хөрмәтле, затлы нәселдән булуыбыз белән чын күңелдән горурланабыз. Кешелек барында бу һөнәр яшәячәк. Бәлки, безнендә балаларыбыз үзебезнең династия эшен дәвам итәр әле.

**Йомгаклау**

Укытучы һөнәре – нинди һөнәр соң ул? Укытучы балаларны язарга, укырга, сөйләргә, мисаллар чишәргә, җырларга, биергә, әти-әниләрне, олыларны һәм дусларны хөрмәт итәргә, әдәпле тыйнак, ягымлы булырга өйрәтә.

Безнең педагогик династиядә 7 укытучылар нәселе – һәм һәрберсе үзенең таң калырлык язмышы белән үзгә булып торуы белән аерыла. Бүгенге көнгә бу укытучылар династиясенең гомуми педагогик стажы – 179 ел. Буыннан буынга бу гаилә әгъзалары укытучы һөнәренең бөек әләмен эстафета итеп тапшырган. Алар төрле фәнне укытканнар һәм укыталар да, ләкин аларны професссиональлек, иҗатка омтылыш һәм бар йөрәген балаларга бирү сыйфатлары берләштерә. Без бу гаиләнең җаваплы, авыр хезмәтенә таң калдык. Бары тик үз эшен яраткан кеше генә шундый уңышларга ирешә ала. Аларның кайсын гына алсаң да, һәркайсы намуслы, эшчән, ярдәмчел,тыйнак, кешелекле, үз дигәненә ирешә торган абруйлы

кешеләр.Хәзерге вакытта да нәсел дәвамчылары бу һөнәргә тап төшерми хезмәт куялар.

Бу педагогик династия районның, шәһәрнең,җөмһүриятнең, хәтта чит илләрнең дә горурлыгы, абруе булып тора. Һәр укытучы – ул олы тарих. Ә тарихны белергә кирәк. Кем безнең белән юк – аларны онытмаска , синең янында яшәүче, кем үз эшенә бөтен җанын бирә – алар турында белергә кирәк. Аны истә тотсалар – бу укытучы өчен иң мөһиме. Чын күңелдән хөрмәт итү һәм ярату шуны исбатлый. Бу авыр җаваплы хезмәтне сайлаучылар алдында без баш иябез. Алар белән горурланабыз! Сүзебезне шигырь юллары белән йомгаклыйсыбыз килә:

Һөнәрләр күп: кем булсаң да: табип, эшче, тукучы...

Тик онытма бер нәрсәне - юл күрсәтә укытучы. Бөек педагог Ян Амос Коменский: «Бу дөньяда укытучы хезмәтеннән дә өстен нәрсә юк»,—дигән.